КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 март г.Казань № 231

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты коллегиясе составын раслау турында» 2010 ел, 25 июнь, 512 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты коллегиясе составы турында» 2010 ел, 25 июнь, 512 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 2 ноябрь, 879 нчы; 2011 ел, 17 март, 200 нче; 2012 ел, 20 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 4 июнь, 380 нче; 2014 ел, 16 декабрь, 993 нче; 2015 ел, 2 апрель, 206 нчы; 2015 ел, 22 май, 366 нчы; 2015 ел, 13 октябрь, 764 нче; 2016 ел, 18 февраль, 102 нче; 2018 ел, 16 гыйнвар, 8 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 7 нче; 2019 ел, 18 ноябрь, 1046 нчы; 2019 ел, 25 декабрь, 1200 нче; 2020 ел, 6 март, 173 нче; 2020 ел, 20 апрель, 308 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 996 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 833 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Тариф буенча дәүләт комитеты коллегиясе санын һәм составын раслау турында»;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбәндәгеләрне расларга:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты коллегиясе санын 19 кеше күләмендә;

бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты коллегиясе составын.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты коллегиясе составында:

коллегия составыннан А.Л.Штромны чыгарырга;

коллегия составына Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Максим Анатольевич Топилинны (килешү буенча) кертергә;

Лариса Васильевна Хәбибуллинаның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары, коллегия рәисе урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин